КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 декабрь г.Казань № 1668

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосалары һәм юл буе полосалары турында» 2008 ел, 1 декабрь, 841 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосалары һәм юл буе полосалары турында» 2008 ел, 1 декабрь, 841 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 18 май, 317 нче; 2014 ел, 25 октябрь, 778 нче, 2018 ел, 20 декабрь, 1186 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасында «Шартнамәләр төзүдән алына торган акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының махсус счетына күчерелә.» җөмләсен төшереп калдырырга;

3 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы" сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятенә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасы чикләре территорияне планлаштыру документлары нигезендә билгеләнә, моңа җир

законнарында каралган очраклар керми. Автомобиль юлларын һәм (яисә) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән территорияне планлаштыру документларын әзерләү күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен җирләр бүлеп бирү нормаларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин